СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18.01.2016** **с.Ямбулатово** **№ 5 – 32**

«Югары Ослан муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының һәм Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетының авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән һәм авыл җирлекләрендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча расланган кагыйдәләр булганда җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге турында килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 августындагы 26-301 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

“Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Уставына таянып,

Югары ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының һәм Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетының авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән һәм авыл җирлекләрендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча расланган кагыйдәләр булганда җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге турында килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 августындагы 26-301 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы

М.Н. Әхмәтҗанов